ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10 09 2019 г. № 541

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2019 елның 19 июнендәге 07-19 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру административ регламентына кертелгән теркәлгән үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
җитәкченең беренче урынбасары Р.И. Беляев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 10-нчы сентябрь
541-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 24 апре-лендәге 212 номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

1. 1.2 пунктының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары (РФ законнары җыелмасы, 31.12.2018, № 53 (II өлеш), 8712 ст.);»;

2. 1.2 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары (РФ законнары җыелмасы, 01.04.2019, № 13, 1427 ст.);»;

3. 1.2 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы («Российская газета», № 85, 14.05.2009);»;

4. 1.2 пунктының унбишенче абзацын төшереп калдырырга;

5. 1.8.8. пунктның 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

6. 2.3 пунктның «д» пунктчасын төшереп калдырырга;

7. 2.5.1 пунктының 2 пунктчасында «планлы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

8. 2.5.2 пунктының беренче абзацында «планлы» сүзен төшереп калдырырга;

9. 3.1 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

10. 3.4.4 пунктын төшереп калдырырга;

11. 3.4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Билгеле бер куркыныч классына (категориясенә) яки билгеле бер риск категориясенә кертү юридик затларның эшчәнлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән билгеле бер риск категориясенә кертү критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

12. 3.4.6-3.4.9 пунктчаларын төшереп калдырырга;

13. 3.6.4 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.4. Тикшерү предметлары булып торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында түбәндәге мәгълүматны урнаштыру тәртибе һәм сроклары тора:»;

14. 3.6.4. пунктчасының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән документлар»;

15. 3.6.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.5. Әлеге Регламентның 3.6.4 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясында каралган тәртиптә ачыла;

16. 3.6.6-3.6.8 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

17. 3.6.13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.13. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 20, 21 статьялары таләпләрен бозулар ачыклаганда, административ регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча тикшерү акты төзелә, һәм административ регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелә.»;

18. 3.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру тәртибе, Административ регламентның 3.8 пунктында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, Административ регламентның 3.7.1, 3.7.3 пунктчалары белән билгеләнгән.»;

19. Административ регламентның 3.7.2, 3.7.4, 3.7.5. пунктчаларын төшереп калдырырга;

20. 3.8.4 пунктчасында «әлеге статьяның 11 өлешенең 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән» сүзләрен «Административ регламентның 3.8.2 пунктының 1, 2, 4, 5 һәм 6 пунктчаларында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

21. 3.9.3. пунктчасында «(планлы һәм планнан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

22. 3.9.4, 3.10.7 пунктчаларында «1.9.1 һәм 1.9.2 пунктлары белән» сүзләрен «1.9.1.1 һәм 1.9.1.2 пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

23. 3.9.13.1 пунктчасында «3-нче кушымта нигезендә» сүзләрен «2-нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

24. 3.9.13.5 пунктның 2 пунктчасында, 3.10.12 пунктның 2 пунктчасында «2-нче кушымта нигезендә» сүзләрен «1-нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

25. 3.9.13.6 пунктчасында «бүлек хезмәткәре булып тора» сүзләрен төшереп калдырырга;

26. 3.10.2 пунктчасында «(планлы һәм планнан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

27. 3.10.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.6. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, аның җитәкчесе яисә юридик затның башка вазыйфаи заты булмау сәбәпле мөмкин булмаса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген фактта башкармауга бәйле рәвештә яисә тикшерүне үткәреп булмауга китергән шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиле, аның җитәкчесе яисә юридик затның башка вазыйфаи затының башка гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле рәвештә, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкин булмавының сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи.

Бу очракта муниципаль контроль органы тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгәннән соң өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш урынга чыгып һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәрнамә бирмичә генә планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы»;

28. 3.11 пунктын төшереп калдырырга;

29. 3.12.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12.5. Россия Төзелеш министрлыгының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары төзелеше (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның үрнәк графикларын һәм килешүләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма туплама исемлеген үтәү турында төзүчеләр тарафыннан контрольлек итүче органга эшчәнлекне башкару турында хисап бирү формасын һәм тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы белән расланган күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектлары төзелеше (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында квартал саен хисап кабул итү буенча административ процедура формалар буенча төзүченең хисап бүлегенә тапшырудан башлана;

30. 3.12.7 пунктында 3.13.6 пунктының бишенче абзацында» сүзләрен «3.12.6 пунктының бишенче абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

31. 3.2.16. пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары таләпләренә төзүченең финанс тотрыклылыгы нормативларының туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра»;

32. 3.12.10. пунктында «3-нче кушымта нигезендә» сүзләрен «2-нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

33. 3.13.4 пунктында «планлы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

34. 3.13.6, 3.13.7 пунктларының 1 пунктчасында тиешле саннарда һәм килешләрдә «торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен тиешле саннарда һәм килешләрдә «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга;

35. 3.13.8 пунктын төшереп калдырырга;

36. 3.14.9 пунктында «имза салына» сүзен «имза сала» сүзенә алмаштырырга, «вәкаләтле вәкил тарафыннан» сүзләрен «вәкаләтле» сүзләренә алмаштырырга;

37. 3.14.11 пунктында «ЭДӘВС» сүзен «электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасында» сүзләренә алмаштырырга;

38. Регламентка 2, 3, 4-нче кушымталарны яңа теркәлгән редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан үтәү буенча административ регламентка
2-нче кушымта

Төзүченең квартал саен хисабын камераль тикшерү (документар)
акты

Керү номеры____ 2019 елның «____» _____________

Төзүченең исеме: _______________________________________________
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Хисап чоры:
Түбәндәге юнәлешләр буенча квартал саен бирелгән хисапка тикшерү уздырылды:

| т/с | Тикшерелә торган мәсьәләләр исеме | Тикшерү ачыклаган |
|---|---|---|
| 1 | Хисапның вакытында бирелүе (датасы) | |
| 2 | Тапшырылган хисапның комплектлыгы | |
| 3 | Дөрес рәсмиләштерү (имзалар, мөһер, тегү) | |
| 4 | Квартал саен бухгалтер хисабы | |

1-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Төзүче турында мәгълүмат | |

2-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 6 | Төзелешкә рөхсәт булу | |
| 7 | Проект декларациясен бастырып чыгару һәм урнаштыру | |
| 8 | Җиргә милек хокукын дәүләт теркәве (арендалау) | |
| 9 | Өлешләп төзелештә төзелгән шартнамәләр турында мәгълүмат | |
| 10 | Өлешләп төзү объектын төзүче тарафыннан тапшыру срогы | |
| 11 | Төзүченең өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсен үтәве турында мәгълүмат | |
| 12 | Өлешләп төзелештә катнашу шартнамәләре | |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт турында мәгълүмат | |
| 14 | Белешмәләр булу | |
| | 7 п. – өзелгән шартнамәләр буенча белешмә | |
| | 11п. - йөкләмәләрнең тиешенчә үтәлмәве турында белешмә | |

3-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 15 | Акча җәлеп итү турында мәгълүматларны анализлау | |
| 16 | Башка чыгымнар (проект документациясенә сылтама белән) | |

4-нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| 17 | а) 2018 елның 1 июленә кадәр төзелешкә рөхсәт алган: | |
| 18 | йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы - кимендә 1 | |
| 19 | чаралардан максатчан файдалану нормативы – 1 дән артык түгел | |
| 20 | б) 2018 елның 1 июленнән соң төзелешкә рөхсәт алган: | |
| 21 | йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы - кимендә 1 | |
| 22 | чаралардан максатчан файдалану нормативы – 1 дән артык түгел | |

Тикшерү нәтиҗәсе

Хисап (кабул ителгән, кабул ителмәгән):__________________________________________.
2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозу ачыкланган_____________________________________________________________.
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы карарының 1-5, 8-13 п. таләпләрен бозу ачыкланган ____________________________».
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карарының түбәндәге өлешендәге таләпләрен бозу ачыкланган

| | | |
|---|---|---|
| 2 п. | а) 2018 елның 1 июленә кадәр төзелешкә рөхсәт алган: | |
| | йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы - кимендә 1 | |
| | чаралардан максатчан файдалану нормативы – 1 дән артык түгел | |
| | б) 2018 елның 1 июленнән соң төзелешкә рөхсәт алган: | |
| | йөкләмәләрне тәэмин итү нормативы - кимендә 1 | |
| | чаралардан максатчан файдалану нормативы – 1 дән артык түгел | |

Актка битләрдә кушымта белән хисап теркәлә.

Финанс базарлары буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 12 гыйнварындагы 06-2/пз-н номерлы боерыгы белән расланган методик күрсәтмәләрнең 1.4 пункты нигезендә хисап формаларын тутырганда рөхсәт ителми:

- хисап формасында күрсәтелгән күрсәткечләрнең мәгънә эчтәлеген үзгәртү;
- хисап формаларының билгеләнгән тәртибен төшереп калдырырга яки үзгәртергә;
- хисап формасының логик структурасын бозып, бер графада берничә күрсәткечне чагылдырырга;
- хисап формаларына төзәтмәләр кертергә.

Хисапны тикшерде: ______________________ (________________________)
(имза) (фамилиясе, инициаллары)


Ачыкланган бозуларны бетерүгә күрсәтмә язып бирелгән:
214-ФЗ номерлы Федераль закон – 2004 ел ________________________________кадәр
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 656/пр номерлы карары – 2018 ел _____кадәр;
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары – 2018 ел ______кадәр.

Хисапта ачыкланган кисәтүләр бетерелде:
214-ФЗ номерлы Федераль закон – 2004 ел :_____________________________________
(әйе яки юк)
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 656/пр номерлы карары – 2018 ел _______;
(әйе яки юк)
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары – 2018 ел ________.
(әйе яки юк)


Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы территориясендә
күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка
күчемсез милек объектларын өлешләп төзү
өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген)
гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен
Түбән Кама муниципаль районы Башкарма
комитеты тарафыннан үтәү буенча
административ регламентка
3-нче кушымта

Блок-схема исполнения государственной функции


1.Организация внеплановых проверок




2. Выездная проверка




2.1 Проведение выездной проверки.



2.2 Обработка результатов выездной проверки





3. Документарная проверка

3.1 Проведение документарной проверки



### 3.2 Обработка результатов документарной проверки



Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы территориясендә
күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка
күчемсез милек объектларын өлешләп төзү
өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген)
гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен
Түбән Кама муниципаль районы Башкарма
комитеты тарафыннан үтәү буенча
административ регламентка
4-нче кушымта

Күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объектлары төзелеше (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында төзүче тарафыннан квартал саен хисап белән бирә торган документлар исемлеге

1. Төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектлары төзелеше (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында квартал саен хисабы.

Төзүче тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яки) күчемсез милекнең бүтән объектлары төзелеше (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның үрнәк графикларын һәм килешүләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма туплама исемлеген  үтәү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органына төзүче тарафыннан хисап бирү Тәртибе нигезендә, хисап составына кертелә:

1) Тәртипләргә кушымта нигезендә формалар буенча хисаплар;

2) хисапта өлешләп төзүдә катнашу шартнамәләре буенча үтәлмәгән (срогы чыккан) йөкләмәләр турында мәгълүмат булганда, йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәүнең сәбәпләрен күрсәтеп, белешмә тапшырыла»;

3) башка чыгымнар булганда, акчаны тоту юнәлешен күрсәтеп һәм акчаны тотуның бу юнәлешен күздә тоткан проект документларына сылтама белән белешмә тапшырыла.;

4) төзүченең Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән квартал саен (IV квартал нәтиҗәләре буенча – еллык) бухгалтер хисабы. Еллык бухгалтерлык хисабы составында төзүче тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып барган соңгы ел өчен аудиторлык бәяләмәсе тапшырыла.

2. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек итүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына гражданнардан төзелеш өчен акча җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан

тапшырыла торган өлешләп төзүдә катнашу шартнамәләре реестры.

3. Күпфатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзелешендә (төзегәндә) төзүче тарафыннан башкарылган эшләр күләме турында белешмә.

4. Тиешенчә расланган күчермәләре (бирелгән белешмәләрне раслау өчен):

- күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзелешенә рөхсәтләр*;

- күпфатирлы йорт һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объекты төзелеше (төзү) өчен бирелгән җир кишәрлеген, дәүләт теркәвенә алу турында тамга белән, милекчелек хокукын һәм (яисә) аренда (субаренда) шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар*;

- өлешләп төзүдә катнашу буенча беренче теркәлгән шартнамә;

-күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез милекнең башка объектын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр*;

- өлешләп төзү объектын төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру турында яклар имзалаган тапшыру акты яки башка документ.

* Күрсәтелгән белешмәләр бары тик төзүче инициативасы буенча гына тапшырылырга мөмкин.